ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУРНАКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОРНАК
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.10.2025 года**

**КАРАР**
**№27**

**Борнак авыл җирлеге территориясендә**
**йорт хайваннары йөри торган урыннарны**
**билгеләү турында**

2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ "Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында", 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында", Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән, "Өстәмә таләпләрне раслау турында" 2023 елның 11 августындагы 971 номерлы "Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын, шул исәптән аларны йөртергә", гражданнарның, хайваннарның куркынычсызлыгын, физик затларның мөлкәтен саклауны тәэмин итүче йорт хайваннарын йөртергә шартлар тудыру максатыннан, Борнак авыл җирлеге Уставы белән, Борнак авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Борнак авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртергә рөхсәт ителгән урыннар:
- хуҗалар кулланылышында яки милегендә булган җир участоклары;
- торак секторларыннан читтә һәм торак булмаган биналар янында урнашкан гомуми куллану территорияләре.

Йорт хайваннарын йөртүне гражданнар, хайваннар куркынычсызлыгы, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең саклануы мәҗбүри тәэмин ителгән очракта башкарырга кирәк.

Медицина, мәгариф һәм физкультура-спорт оешмалары территорияләрендә, гражданнар йөзү өчен рөхсәт ителгән пляжларда һәм йорт хайваннары белән булу законнар белән тыелган башка территорияләрдә йорт хайваннары белән булу тыела.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Бу карар рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Борнак авыл җирлеге
башкарма комитетынын җитәкчесенен
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы О.Г.Андреева